Ноябрь • 2020 ел • № 5 (35)
minem-gimnaziyam.jimdo.com

# Минем гимназиям

2 нче ГИМНАЗИЯ

«М. Вахитов исемендәге 2 нче гимназия» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе газетасы

# Татарстан Президенты безнең гимназиядә!

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Чаллыда Мулланур Вахитов исемендәге 2 нче гимназиядә булды, ул балаларны тукландыруны оештыру белән танышты. Ул ашханәне карады, ассортимент белән танышты, мәктәптә бирелә торган ашларны татып карады. Рөстәм Миңнеханов Чаллы мәктәбе ашханәсендә кайнар ризыкның сыйфатын югары бәяләде. Бу турыда республика җитәкчесенең матбугат хезмәте хәбәр итте.



Бүгенге көндә гимназиядә 810 бала белем ала. Быел гимназиядә капиталь ремонт үткәрелде. Җиһазлар һәм җиһазларны ремонтлау һәм сатып алу өчен республика бюджетыннан 176 млн сум акча бүлеп бирелгән. Рөстәм Миңнеханов уку сыйныфларын, спорт залын, көрәш белән шөгыльләнү залын, башлангыч сыйныфлар кабинетын карап чыкты.

Капиталь ремонт кысаларында ашханә бүлмәләре дә яңартылган. Азык-төлек блогындагы җиһазларны тулысынча алыштырганнар, камырдан ризык пешерү һәм яшелчә цехларын модернизацияләгәннәр.

Искәртеп узабыз, Федераль Җыенга Юлламасында Россия Президенты Владимир Путин 2020 елның 1 сентябреннән кече сыйныф укучылары өчен түләүсез кайнар ризык кертүне йөкләде. Чаллыда әлеге исемлеккә 31,8 мең мәктәп укучысы керә.

Автошәһәрнең кайнар ризык белән тәэмин итүче төп оешмасы – «Мәктәп туклануы» ҖЧҖ. Компания шәһәрнең 78 мәктәбеннән 74 нче мәктәбенә үз хезмәтләрен күрсәтә, шул исәптән Мулланур Вахитов исемендәге 2 нче гимназиягә дә.

Чыганак: Татар Информ












# «Бика-фест» дусларын җыйды

Рөстәм Бикмуллин исемендәге XIX Республикакүләм яшьләр җыр-шигърият фестивале быел янәдән сәнгать яратучы яшьләрне Сәләт Йортына җыйды. Татарстанның төрле районнарыннан килгән 350 артык егет һәм кыз җыр һәм нәфис сүзгә осталыгын күрсәтте. Фестиваль «Сәләт»нең якын дусты, бард җырчысы Рөстәм Бикмуллинның исемен мәңгеләштерү максатыннан быел 19 нчы тапкыр үткәрелә.

Гадәттәгечә, бәйге музыка һәм әдәбият юнәлешендә узды. Катнашучылар үзләрен төрле номинацияд҆ә сынап карый алдылар. Аларга танылган җырларны башкарырга, үзләре иҗат иткән музыкаль һәм әдәби әсәрләрне тәкъдим итәргә, коллективлары белән чыгыш ясарга мөмкинлек бирелде. Быел яңа номинация – «Татар җыры стилизациясе» өстәлгән иде. Катнашучылар быел беренче мәртәбә татар җырларын яңача яңгыраштә тәкъдим итте.

Мин әлеге фестивальдә икенче тапкыр катнаштым, узган ел «Башка автор әсәрен яттан иң оста укучы (12–15 яшь)» номинациясендә Һ.Такташның «Алсу» поэмасын яттан сөйләп призер булган идем, быел Ә.Еникинең «Мәк чәчәге» хикәясеннән өзек сөйләп, җиңүче дип табылдым. Әлбәттә, мин бик сөендем, жюри әгъзалары Рәмис абый Әймәт, Йолдыз апа Миңнуллина, бик игътибарлы икәннәр: алар минем узган елгы чыгышымны хәтерләүләрен әйттеләр, хәтта үзләре биргән киңәшләрне тотып, әсәрдән өзекне сөйләвемне билгеләп уздылар.

Фестиваль кысаларында музыка юнәлешендә казый булган җырчылар Зәйнәп Фәрхетдинова, Римма Ибраһимовалар белән очрашу булды. «Актерлык осталыгы» буенча дәресләрне танылган актриса Резеда апа Сәлахова уздырды. Бәйгенең беренче турын узганнан соң, икенче көн бик дулкынландыргыч булды, чөнки бәйгенең нәтиҗәсе соңгы минутка кадәр сер булып саклана. Ул көн минем өчен шоу-концерт уздыру остаханәсендә кунакта булган кеше хисләре буларак хәтеремдә калды. Беренче турда җиңгән катнашучылардан тиз арада «Квартирник» проекты форматында концерт әзерләнде, репетиция ясалды. Бу гаҗәеп тупланган команда эшенә бик сокландым.

«БикаФест» фестивалендә Гранприга – «Тормыш җыры»н башкаручы Инсаф Ганибаев лаек булды. Шулай ук махсус бүләкләр дә бар иде. Барлык җиңүчеләргә дә «БикаФест»ның партнерларыннан кыйммәтле бүләкләр һәм дипломнар тапшырылды.

**Алия НУРИСЛАМОВА**







Республикакүләм «Татар кызы – 2020» бәйгесенең зона этабы Яр Чаллы каласында узды. Әлеге бәйгенең мөхтәрәм жюри әгъзалары гимназия белән танышып чыгарга вакыт таптылар. Килгән делегация составында Халыкара «Татар кызы» бәйгесе дирекциясе башкарма директоры Гыйниятуллина Гүзәлия Шамил кызы; Бөтендөнья татар хатын-кызлары форумы җитәкчесе, Региональ татар хатын-кызларының «Ак калфак» иҗтимагый оешмасы



# «Ак калфакның табылган чагы...»



рәисе Идрисова Кадрия Рәес кызы; Татарстан Республикасының Халык артисты Закирова Чулпан Ринат кызы; телевидение дикторы, Казан театр һәм музыка укуханәләре мөгаллиме, Татарстан Республикасының Атказанган артисты Абдуллин Инсаф Фәрүт улы бар иде.

Әлеге форсаттан файдаланып, кунаклар «Минем гимназиям» газетасы белән таныштылар. Башкарган эшебезнең тирән эчтәлекле, зәвыклы, иҗади булуын ассызыклап уздылар. Газетаның башлангычында торган Әюпова Фирдүсә Фәнәвисовнаның күзләреннән горурлык чаткыларын күрергә мөмкин иде, чөнки газета сериясеннән чыккан җыентыклар кунакларда аеруча кызыксыну тудырдылар. Кадрия Раесовна 2018 нче елда «Ак калфак» бәйгесендә катнашып, җиңеп чыккан кызлар Гыйльманова Алсу белән Әмирова Гүзәлне хәтергә төшереп узды, кызларның милли рухта тәрбияләнгәнлекләренә басым ясады. «Мондый мохиттә, шушындый мөгаллимнәр барында туган телебез саклана-чак», – дип рәхмәтен белдерде.

**Энҗе Әзһәм кызы НУРИСЛАМОВА**

**Яшь каләм тибрәтүчеләргә киңәшләр**

Остаханә

# Кулга каләм алгач...

Сине нинди дә булса табигать күренеше таң калдырдымы? Гадәттән тыш хәл игътибарыңны җәлеп иттеме? Берәр әңгәмә вакытында яңа уйлар тудымы? Һәм синдә бу кичерешләрне сүзләргә төреп, башкаларга җиткерү теләге уяндымы?

Ничек бу эшкә тотынырга соң? Нәрсәдән башларга? Язу осталарының берничә киңәшен генә тыңласаң да, язмаларың күпкә җанлырак, тирәнрәк, кызыклырак булыр.

1. Нәрсәнедер тасвирларга телисең икән, аны башта ачык итеп күз алдына китер. Син ул вакыйганы бөтен төсләре, тавышлары, вак кына детальләренә кадәр, кино караган кебек, экранда күрергә тиеш.

2. Үзең ничек күрәсең, ничек ишетәсең, шулай сурәтлә. Тукай күзләре үткен, күзәтүчән, билгеле, ләкин тагын бер кешенең дөньяга шул ук күзләр белән каравы беркемгә дә кирәкми.

3. Образлы сүзләр тап, чагыштырулар куллан. Мәсәлән, кук күкрәвен Чехов өй түбәсеннән яланаяклы малай йөгереп узу белән чагыштыра.

4. Беркайчан да «бармактан суырып» язма. Рәссам турында язасың икән, аның остаханәсенә бар, ничек эшләвен күзәт, сөйләм үзенчәлекләрен өйрән, аңа гына хас ишарәләрен исеңдә калдыр.

5. Бу язмаң белән нәрсә әйтергә теләвеңне ачыкла.

6. Язучы, телиме ул, теләмиме, әсәрләрендә үзенең эчке дөньясын чагылдыра. Шулай булгач, яхшы әсәр язар өчен, үзеңне яхшыртырга омтыл, эчке дөньяңны баетырга тырыш. Моның өчен күп күрергә, күп ишетергә, күп уйларга, күп укырга кирәк.

7. Тема каян алырга соң? Бер тема һәрвакыт синең өеңдә. Кешенең тормышында шулкадәр вакыйга була, алар бер китапка гына да сыеп бетмәскә мөмкин. Әби-бабайларың, эти-әниең исән чакта алар белән сөйләшеп, язмышларын белеп кал, азактан үкенерлек булмасын.

**Марс ЯҺҮДИН,**
*ТатарстанЯзучыларберлегеәгъзасы.*

(В. Вересаев һәм А. Куприн киңәшләренә таянып әзерләнде.)

*Исәнме, безнең яраткан «Минем гимназиям» газетасы!*

*Без гимназиянең 3 В сыйныфында укыйбыз. Синең белән очрашуны сагынып көтеп алабыз. Газета битләрендә укучыларның шигырьләрен, әкиятләрен, төрле рубрикаларны яратып укыйбыз.*

*Әдәби уку дәресендә укытучыбыз Илфира Сабировна безгә рифма турында аңлатты да, «Ә бер генә юллы яки өч юллы шигырь буламы?» – дип сорап куйды. Без аптырап калдык. Була икән! Равил абый Фәйзуллинның «Кышын», «Кышкы бакчада» шигырьләрен укыгач, ышандык. Үзебезнең дә шигырь язып карыйсыбыз килде һәм шуларның кайберләрен сиңа юлларга булдык. Иҗат җимешләребезне кадерле дустыбыз «Минем гимназиям» газетасы битләрендә күрсәк, бик шатланыр идек.*

## Кыш нигә кирәк?

Кыш нигә кирәк?
Кирәктер, бәлки туңдырырга.
Бөтен җирне катырырга,
Бураннарын туздырып,
Ак карларын очырып,
Һәр тишеккә тутырырга.
Кыш нигә кирәк?
Елга-күлне боз итеп,
Балаларны шудырырга.
Тәрәзәгә бизәк ясап,
Армас-талмас рәссам булып,
Синдә, миндә – һәркемдә
Ак хыяллар тудырырга.

**Амилә ЗАКИРОВА**

## Сагындым кышны

Мин бик яратам кышны!
Сагындым Яңа елны,
Өй янындагы зур тауны,
Тимераяк, чаңгы, чананы.

Тик кыш быел бик саран
Бик аз ява кары да.
Малайлар, җәй диярсең,
Футбол тибә урамда.

**Камилла ГИБАДУЛЛИНА**

## Кышны көтү


Җәй үтеп көз җиткәч,
Карлы кышларны көтәм.
Чаңгы бүләк итсәләр,
Шуарга чыгып китәм.

**Азалия НАСРЕТДИНОВА**

## Кыш

Менә салкын кыш килде.
Җиргә ап-ак кар яуды.
Шатланышып балалар
Чаңгы, чанада шуды.

**Ләйсән НУРИЕВА**







## Нигә бездә бар йөрәк?

– Нигә бездә бар йөрәк?
– Чөнки ул безгә кирәк.
– Ә нигә кирәк йөрәк?
– Илне сакларга кирәк,
Батырлыклар эшләргә,
Көчсезләрне якларга,
Табигатьне тоярга
Һәм дөньяны бизәргә
Йөрәк кирәк безләргә.

**Луиза ГАФИЯТОВА**

## Әни

Әни – иң якын кеше.
Безне үбеп уята.
Әни йомшак күңелле,
Ул безне бик ярата.

**Әдилә ӘҮХӘДИЕВА**

## Песием

Песи белән уйныйм мин,
Песи белән йоклыйм мин,
Песи белән шаярам.
Исеме аның – Шаян.

**Алсу ЯГУДИНА**

## Телефон

Әниемнән сорыйм мин:
«Телефон нигә кирәк? »
Әнием миңа дәшә:
«Уен уйнарга түгел,
Сөйләшер өчен кирәк».

**Закир ГАНИЕВ**



Минем гимназиям
**Баш мөхәррир** Алия НУРИСЛАМОВА • **Редакция әгъзалары:** Азалия ӘМИНОВА • Адилә ХАНОВА • Мәрьям РИЗАТДИНОВА • Әминә ШАКИРОВА • Данис ДАМИНОВ • Ләйсән КӘРИМОВА • Камилла ЮСУПОВА •
• **Редактор-координатор:** Э. А. НУРИСЛАМОВА